**Садыйков Айзирәк Марсель улы**

# Ябык орлыклы (Чәчәкле) үсемлекләр бүлеге

**Исәнмесез, хөрмәтле укучылар!**

**<u>Слайд 1</u>. Бүгенге дәрестән без Ябык орлыклы яки чәчәкле үсемлекләр бүлеген өйрәнә башлыйбыз.**

**Искә төшерегез, үсемлекләрнең табигатьтә һәм кеше тормышында әһәмияте нидә? Әлбәттә, беренче чиратта, аларның барлык тере организмнарның сулавын тәэмин итүче кислород бүлеп чыгаруында. Икенчедән, үсемлекләр терек булмаган табигатьнең неорганик матдәләреннән органик матдәләр синтезларга сәләтле. Өченчедән, культуралы, техник, декоратив үсемлекләрнең дә роле гаять зур.**

**Без үсемлекләрнең зур бер төркеме- Чәчәкле үсемлекләрне өйрәнүгә керешәбез. Аларның 250 меңгә якын төре исәпләнә.**

**<u>Слайд2.</u>** Болар – Җир йөзендә киң таралган үсемлекләр. Алмагач, чия, имән, энҗе чәчәк, үги ана яфрагын һәм башка үсемлекләрне барыгыз да белә.

**<u>Слайд 3.</u>**Чәчәкләр, үсегез, чәчәкләр,
Дәрт биреп безнең шат күңелгә.
Сезгә бу шатлыклар, рәхәтләр
Бит җиңеп алынган гомергә. – дип язган герой-шагыйрь Муса Җәлил.

**<u>Слайд 4.</u>** Чәчәкләргә сокланмаган, аларның матурлыгына исе-хушы китмәгән кеше юктыр. Сез чәчәкләргә карапниләр хакында уйлыйсыз?

**<u>Слайд 5.</u>** Ни өчен чәчәкле үсемлекләрне ябык орлыклы дип атыйлар? Чәчәк – орлыктан үрчү органы. Чәчәктән серкәләнү һәм аталану нәтиҗәсендә җимеш, ә җимеш эчендә орлыклар формалаша. Димәк, орлыкларны җимеш саклап-каплап тора.

**<u>Слайд 6.</u>**Әйдәгез, ябык орлыклы үсемлекләрнең төп билгеләре белән танышыйк:

1. Ябык орлыклы үсемлекләрнең 250 мең төре бар;
2. Аларның органнары үсеш алган (тамыр, сабак, яфрак, чәчәк);
3. Чәчәкләре бар, шуңа да аларны чәчәкле үсемлекләр дип тә атыйлар;
4. Җимешләре бар. Җимеш чәчәктән серкәләнү һәм аталану нәтиҗәсендә барлыкка килә;
5. Күптөрле экологик шартларга әйбәт яраклашканнар;
6. Серкәләнү җил ярдәмендә, яки бөҗәкләр, кошлар һәм башка хайваннар катнашында башкарыла;

7. Төрле яшәү формаларына ия: үләннәр, куаклар, агачлар.

**Чәчәкле үсемлекләрне берьеллык, икееллык һәм күпьеллыкларга бүләләр. Берьеллык үсемлекләрнең яшәү циклы (үсү, чәчәк ату, орлык калдыру, үлү) бер вегетацион период эченә сыя.**
**Слайд 7.** Бу: Мәк, Кукуруз, Кыяр, Җитен, Кычыткан һәм башка үсемлекләр. Бу үсемлекләрнең орлыгы, гадәттә яз көне шытып чыга; үсемлек бик тиз үсеп җитә, чәчәк ата, җимеш һәм орлык бирә, шуннан соң корый.

**Икееллык үсемлекләрнең яшәү циклы 12айдан 24айга кадәр дәвам итә.**
**Слайд 8.** Кишер, Кәбестә, Чөгендер, Шалкан, Канәфер кебек үсемлекләр икееллык дип атала. Беренче елда алар вегетатив органнарын үстерә, тамыр һәм сабакларында туклыклы матдәләр туплый. Икенче елда генератив органнар формалаша, алар чәчәк ата, җимеше-орлыклары өлгерә, шуннан соң алар корый.

**Яшәү циклы ике елдан артык вакытны алган үсемлекләрне күпьеллык дип атыйлар.**
**Слайд 9.** Мәсәлән, Ромашка, Энҗе чәчәк, Имән, Карлыган, Сирень – күпьеллыклар. Әлеге үсемлекләр беренче елларда чәчәк атмый, чәчәкләре орлыктан шытып чыкканнан соң 5-10 елдан соң гына формалаша.

**Дәресебезнең практик өлешенә керешик.**

**Слайд 10.** 1).Чәчәкле үсемлекләр сезгә инде яхшы таныш. Алар табигатьтә һәм кеше тормышында нинди роль башкаралар?

**Слайд 11.** Дөрес, җавапларыгызны гомумиләштереп киләсе фикерләргә тукталырга була:
-Алар кеше өчен ризык булып тора (Яшелчәләр, җиләк-җимеш, май, икмәк культуралары);
-Сәнәгать өчен чимал (җитен, мамык, шикәр чөгендере);
-Авыл хуҗалыгы хайваннары өчен азык (азык чөгендере, турнепс);
-Декоратив әһәмият;
-Дару үләннәре.

**Слайд 12.** 2).Бу нинди үсемлек?

- Әлеге үсемлеккә багышлап XX гасыр башында Франциядә бәйрәмнәр уздырганнар, һәм П.И.Чайковский аңа үз әсәрен багышлый.

-Риваятькә ышансак, Алла бар тереклеккә якшәмбе көнне ял итәргә боера, ә бал кортлары бу боерыкны үтәми. Шуңа да алар әлеге үсемлекнең нектарын эчми, бу үсемлекне бары тик төклетуралар гына серкәләндерә.

-Әлеге чәчәк инкыйлаб символы булып сайланган.

**Слайд 13.** Дөрес җаваплар: Энҗе чәчәк, Тукранбаш, Канәфер.

**Слайд 14.** 3) Хаталарны табыгыз.

**Слайд 15.** Җавап:

1.Чәчәкле үсемлекләр – югары төзелешле үсемлекләр, аларның чәчәкләре, орлыклы җимешләре була.

2.Чәчәкле үсемлекләрнең төрле формалары бар: бу берьеллык, икееллык һәм күпьеллык үсемлекләр.

3.Чәчәкле үсемлекләрне икенче төрле ябык орлыклы дип атыйлар.

4.Бу үсемлекләрнең эволюцион күзлектән иң яшь һәм күп санлы төркеме.

**Слайд 16.** 4). Уйлап карагыз. Ни өчен кыр үләннәре саклауга мохтаҗ?
**Слайд 17.** Күпчелек кыр үләннәре, мәсәлән, Ромашка, Кыңгырау чәчәк, Сары мәтрүшкә – күпьеллыклар. Шуңа да алар бер ел эчендә орлык биреп үсеп җитешә алмый. Моңа озак вакытлар, уңай шартлар кирәк була. Чәчәкләрне өчеп без аларны орлыклары өлгерүдән мәхрүм итәбез.

**Слайд 18.** 5).Чәчәкле үсемлекләрнең бирелгән исемлектәге органнарын рәсемнең билгеләмәләре итеп урнаштырыгыз.

**Слайд 19.** Бик әйбәт. Үсемлекләрнең органнарын тирәнтен өйрәнүгә киләсе дәресләребезне багышларбыз.

**Күпчелек үсемлекләр игътибарга, саклауга мохтаҗ. Аларны өзмичә, үсеп утырган матурлыгына сокланырга күнегик, матур чәчәкләрне фотога төшерергә өйрәник.**

**Киләсе очрашуларга кадәр!**